**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево,
423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай
шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«19» октябрь 2021 ел** **№ 263**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы «2020-2025 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 88 нче номерлы «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 03 февралендәге 52 нче номерлы «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 нче номерлы "Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" дәүләт программасын раслау турында" карары белән расланган, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 25 сентябрендәге 916 номерлы «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» ярдәмче программасына 3 нче кушымтага үзгәреш кертү турында» карары нигезендә, карар итә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 345 номерлы карары белән расланган, «2020-2025 елларга Азнакай муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. "Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программа чараларын финанслау федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән планлаштырыла, финанслау күләме дәүләт заказчысы - Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан бүлү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

| ел | Күздә тотылган акча күләме-мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | Татарстан | Федераль | Бюджеттан |

| | Республикасы бюджеты | бюджет | тыш чыганаклар |
|---|---|---|---|
| 2020 | - | - | - |
| 2021 | 562 462,25 | 116 917,15 | 1 585 218,6 |
| 2022 | * | * | * |
| 2023 | * | * | * |
| 2024 | * | * | * |
| 2025 | * | * | * |

* Чараларны финанслау күләме Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча ел саен ачыкланырга тиеш.

1.2. 33 пунктның беренче абзацында түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә:

«Социаль түләү алу хокукы турындагы таныклыкны алыштыру турындагы гариза әлеге таныклыкны язма рәвештә яки электрон формада бердәм портал аша биргән җирле үзидарә органына тапшырыла.»;

1.3. 35 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Сатып алына торган торак бина (шул исәптән өлешләп төзү объекты булып тора) Татарстан Республикасы территориясендә торырга яки торак йорт төзелеше алып барылырга тиеш.».

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Идарә» дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов